Республика Татарстан
Старо-Имянское сельское
поселение Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль
районы Иске Имән
авыл жирлеге

КАРАР
02.10.2017

КАРАР
№ 66

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Иске Имән авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Иске Имән авыл жирлеге Уставының 11 статьясы, «Референдум уздыруны инициацияләү турында» 2018 елның 19 сентябрендәге 64 номерлы карары нигезендә, Иске Имән авыл жирлеге Советы карар итте:

Иске Имән авыл жирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча 2017 елның 19 ноябренә җирле референдум билгеләргә.

1. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

"2018 елда үзара салым чараларын Иске Имән авыл жирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә кертүгә сез килешәсезме, моңа I төркем инвалидларыннан, ашыгыч хәрби хезмәт итүче гранҗданнардан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән дә килешәсезме:

1)Ял вакытын оештыру һәм жирлектә яшәүчеләрне мәдәният оешмаларының хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру:

- Иске Имән һәм Сарысаз-Тәкемән авылларында “Сабантуй”, “Өлкәннәр көне”, “Яңа ел” бәйрәмнәрен уздыру өчен бүләкләр алу;

2) Җирлек территориясен төзекләндерү (урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерүне дә кертеп), шул исәптән:

- Иске Имән һәм Сарысаз Тәкермән авылларында урамнарны яктырту лампаларын алыштыру;

- Иске Имән авылында һәйкәл һәм койма ремонтлау өчен буяу сатып алу;;

- Иске Имән һәм Сарысаз-Тәкермән авылларында яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру);

- Иске Имән һәм Сарысаз-Тәкермән авылларындагы памятниклар өчен краска сатып алу;

- Иске Имән авылында балалар урам комплексы сатып алу;
- Иске Имән һәм Сарысаз Тәкермән авылларында зур агачларны кисү; -Беларус-МТЗ 320.4-с махсус техникасын тоту;
- Иске Имән авылында вакытлыча көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар жыю урыннарын чистарту;
-Сарысаз Тәкермән т.п. көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар жыю урыннарын чистарту.
3) автомобиль юлларына, җирле әһәмияттәге күперләргә карата юл эшчәнлеге, шул исәптән торак пунктлар чикләрендә дә:
- Иске Имән һәм Сарысаз Тәкермән авылларында юлларны кардан чистарту.

«ӘЙЕ» " ЮК»

2. Мәгълүмат стендларында һәм Иске Имән авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә әлеге карарны игълан итәргә.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Ә.Исламова